РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«23» декабрь 2021 ел

г. Альметьевск

№ 1899

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының «2018-2028
елларга Әлмәт муниципаль районы
транспорт инфраструктурасын
комплекслы үстерү» муниципаль
программасын раслау турында» 2018
елның 16 июлендәге 988 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2018-2028 елларга Әлмәт муниципаль районының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү» муниципаль программасын финанслау лимитларын төгәлләштерү белән бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2028 елларга Әлмәт муниципаль районы транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 988 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 сентябрендәге 1315 номерлы, 2018 елның 25 декабрендәге 2253 номерлы, 2019 елның 26 декабрендәге 2270 номерлы, 2020 елның 9 декабрендәге 1806 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

программа паспортының 8 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программа буенча финанслауның гомуми күләме 7 006,84 млн сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- Федераль бюджет акчаларыннан 112,5 млн сум;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан 2 538,5 млн сум; |

Зак. № 305-2000

| | |
|---|---|
| | - муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан 444,3 млн сум;<br>- бюджеттан тыш чыганаклардан 3 911,54 млн сум.<br><br>Искәрмә: Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |

IV кисәкнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018-2028 елларга программаны финанслауның гомуми күләме 7 006,84 млн сум тәшкил итә, шул исәптән:
- Федераль бюджет акчаларыннан 112,5 млн сум;
- Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан 2 538,5 млн сум;
- муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан 444,3 млн сум;
- бюджеттан тыш чыганаклардан 3 911,54 млн сум.»;

муниципаль программага 1 нче кушымтаның 2, 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Юл фонды чаралары һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән шәһәрнең урам-юл челтәрен (ясалма корылмаларны) норматив хәлгә китерү | 2018-2028 | 3 152,3 | 402,3 | | | | Район Башкарма комитеты |
| | | 2018 | 284,3 | 34,3 | | | | |
| | | 2019 | 288,4 | 38,4 | | | | |
| | | 2020 | 290,3 | 40,3 | | | | |
| | | 2021 | 299,2 | 49,2 | | | | |
| | | 2022 | 284,3 | 34,3 | | | | |
| | | 2023-2028 | 1 705,8 | 205,8 | | | | |
| 3. | Күпбалалы гаиләләр өчен торак төзелеше өчен бүлеп бирелгән җир кишәрлекләренд ә керү юлларын төзү | 2018-2028 | 42 | 42 | | | | Район Башкарма комитеты |
| | | 2018 | 0 | 0 | | | | |
| | | 2019 | 0 | 0 | | | | |
| | | 2020 | 0 | 0 | | | | |
| | | 2021 | 0 | 0 | | | | |
| | | 2022 | 6 | 6 | | | | |
| | | 2023-2028 | 36 | 36 | | | | |

муниципаль программага 1 нче кушымтаның «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы: | | 7 006,84 | 444,3 | 2 538,5 | 112,5 | 3 911,54 | |

муниципаль программага 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018-2028 елларга программаны федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслау күләмнәре

(млн. сум, 2018 ел бәяләре буенча)

| Финанслау чыганагы | гомуми сумма | 2019 - 2028 |
|---|---|---|
| Федераль бюджет чаралары | 112,5 | - |
| Татарстан Республикасы бюджеты чаралары | 2 538,5 | 2 140,0 |
| Муниципаль берәмлек бюджеты чаралары | 444,3 | 410,0 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар акчалары | 3 911,54 | 3 508,0 |
| Барлыгы: | 7 006,84 | 6 058,0 |

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ